# Пәйгамбәребезнең ﷺ кыскача тормыш

| | |
|---|---|
| Исем-нәселе: | Әтисе  Габдуллаһ, бабасы Габдел-Мутталиб, ә бабасының әтисе Һәшим исемеле була. Һәшим исә курайшлардан, ә курайшлар – Ибраһим улы Исмәгыйль нәсебеннән килгән гәрәпләрдән булалар. |
| Туган елы: | Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәдә Фил елының Рабигуль-Әүүәл аенда туып, алтмыш өч ел гомеренең  кырыгын – пәйгамбәрлек алдыннан, егерме өчен - пәйгамбәр һәм илче  булып уздыра. Әтисе ул туганчы үлеп, Пәйгамбәребез ﷺ ятим кала. Бабасы Габдел-Мутталиб аны үз тәрбиясе астына ала. Соңыннан ул да үлгәч ул ﷺ абыйсы Абу Талибка күчә. |
| Аның ﷺ җибәрелүе | Пәйгамбәребез ﷺ җеннәргә һәм кешеләргә җибәрелә. Һәм кемгә дә булса аның дәгъвәте килеп җиткәннән соң ул кеше иман китермәсә, бу кеше олы көферлек кылган булып санала. |
| Дәгъвәте: | Ул ﷺ тәүхидкә, күркәм холыкка, изге гамәлләргә чакырып, ширектән, ямсез холыктан һәм начар гамәлләрдән тыя. |
| Әль-Исра үә-ль-Миграҗ: | Башта Мәккәдән Мәкдискә күчерелеп, соңыннан җиде кат күккә күтәрелә.  Һәм шунда Аллаһ аның ﷺ белән сөйләшеп, аңа ﷺ һәм аның ﷺ өммәтенә биш вакыт намаз фарыз кылына. |
| Күчеп китүе һәм вафат булуы: | Мәккәдән Мәдинәгә күчеп китә. Соңыннан шунда вафат булып, мөэминнәрнең әнисе Гаишә бүлмәсендә җирләнә. |
| Динне җиткерүе: | Динне иң яхшы рәвештә тапшырып әманәтне үти. Өммәтенә нәсыйхәт биреп, Аллаһ юлында нинди генә җиһәт булмасын, барысын да җиренә җиткереп кыла. Беркемгә дә шушы дингә нәрсә дә булса өстәргә ярамый. |
| Иң мөһим сугыш походлары: | Бәдр, Ухуд, аль-Хандәка, Хайбар, Мәккәне ачу, Табук, Хунәйн. |
| Балалары: | Касыйм, Ибрахим, Габдуллаһ, Зәйнәб, Рукаййа, Умму Көлсем, Фатыйма. Фатыймадан башка аларның барысы да Пәйгамбәребез ﷺ исән чагында вафат булалар. Фатыйма ул үлгәннән соң ярты елдан соң вафат була, Аллаһ аларның барысыннан да разый булсын. |
| Аның хатыннары: | Хадичә, Гайшә, Сәүдә, Хафсә, Зәйнәб әл-һәләлиййә, Һинд, Җәхшның кызы Зәйнәб , Җүвәйрия, Сафиййә, Рамлә, Райхәнә, Мәймүнә, Аллаһ алардан разый булсын. |
| Аны ﷺ имезүчеләр: | Әнисе Әминә, Абыйсы Әбү Ләһәб коллыктан азат иткән хатын - Сүвәйбә һәм Хәлимә. |
| Пәйгамбере безгә ﷺ иң беренче нәрсә иңдерелә? | Галәкъ сүрәсеннән аятьләр:<br>ٱقۡرَأۡ بِٱسۡمِ رَبِّكَ ٱلَّذِى خَلَقَ 1) خَلَقَ ٱلۡإِنسَٰنَ مِنۡ عَلَقٍ 2) ٱقۡرَأۡ وَرَبُّكَ ٱلۡأَكۡرَمُ 3) ٱلَّذِى عَلَّمَ بِٱلۡقَلَمِ 4) عَلَّمَ ٱلۡإِنسَٰنَ مَا لَمۡ يَعۡلَمۡ 5) |
| Иң беренче иман китерүчеләр: | ирләрдән – Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, хатын-кызлардан – Хадичә бинту Хувайлид, яшьләрдән – Гәли ибну Әби Талиб, хезмәтчеләрдән – Зәйд ибну Хәрисә, коллардан – Биләл ибну Рабәх. |
| Хаҗ һәм гөмрә кылуы: | Үз гомерендә Пәйгамбәребез дүрт тапкыр гөмрә кыла, һәм алар барысы да Зөл Кагъдә айларында була. Бер тапкыр хиҗрә елының уналтынчы елында хаҗ кыла, һәм бу хаҗ саубуллашу хаҗы дип атала. |
| Пәйгамбәребезнең ﷺ холкы: | Мөэминнәрнең анасы Гаишә (Аллаһ аңардан разый булсын): «Аның холкы Коръән иде»,- дип әйтте. |
| Пәйгамбәребезнең ﷺ тормыш юлын өйрәнүнең әһәмияте: | Ибну Каййим әйтте: "Әгәр кешенең ике дөньяда булган бәхете Пәйгамбәребезнең ﷺ юлы белән бәйле икән, үз-үзенә хәерлелек теләп отышта булырга теләүче һәрбер кешегә Пәйгамбәребезнең юлын, яшәешен, сыйфатларын, җәһиллектән чыгуга сәбәп булучы  һәм шулай ук аңа буйсынган кешеләр санына кертүче гамәлләрен белү мәҗбүри булып тора. Һәм кешеләр бу мәсьәләдә өч төркемгә, ягъни Пәйгамбәребезнең ﷺ тормыш юлын аз гынә өйрәнүчеләргә, яисә артыгыннан тыш күп итеп өйрәнүчеләргә я инде бөтенләй игътибар бирмәүчеләргә  бүленәләр. Барлык  дәрәҗә дә Аллаһ кулында, һәм Ул аны кемгә теләсә шуңа бирә. Һәм Аллаһ зур дәрәҗә ия. |